**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.05.2026 № 567

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 11 маендагы 337 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив хокукый актларны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 28 сентябрендәге 1708 номерлы карарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 11 маендагы 337 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 27 маендагы 305 номерлы, 2020 елның 5 октябрендәге 788 номерлы, 2023 елның 20 ноябрендәге 1513 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы Нигезләмәдә:

7 пунктның өченче абзацында «янгын сүндерү, " сүзен төшереп калдырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә туры килә торган бина күпфатирлы йорт дип таныла.»;

45 пунктта «яраклылыгы (яраксызлыгы) турында» сүзләреннән соң «торак» сүзен өстәргә;

47 пунктта дүртенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләрнең булмавы турында;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин